ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26 03 2025 г. № 345

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль районның торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләү методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 июнендәге 430 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак урыннан файдалануга түләү күләмен исәплүү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

нигезләмәнең 1 пунктындагы тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны наемга алган өчен түләү коэффициенты күләме - 0,061, дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урынын наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны наемга алган өчен 0,061 күләмендә билгеләнә».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Г. Парамоновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874